Дәрес темасы: «Дуслар белән күңелле!»
Дәрес тибы: ЛГКК, БСҮ.
Максат:
1. Белем бирү максаты: дуслык темасына карата өйрәнелгән лексик – грамматик материалны ныгыту, системага салу, эшчәнлекне планлаштыру, аны тормышка ашыру юлларын эзләү, нәтиҗә ясау.
2. Үстерү максаты: укучыларның фикерләү сәләтен, тыңлап аңлау, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү, сүзләрне үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.
3. Тәрбияви: дуслыкның кешеләр арасында иң мөһим сыйфат булуына ышаныч формалаштыру.
<u>Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре</u>
Шәхси УУГ:
-укуга карата кызыксыну хисе;
-үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
-нәтиҗәләргә үзанализ һәм үзконтроль.
<u>Метапредмет нәтиҗәләр</u>
Регулятив УУГ:
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып эшләү;
-укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
-эшләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
-биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү (укытучы ярдәмендә).
Коммуникатив УУГ:
-тормыш тәҗрибәсен куллану;
-башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
-парларда,төркемнәрдә эшли белү
Танып-белү УУГ:
-укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирү;
-рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
Җиһазлау: рәсемнәр, биремле карточкалар, ситуатив күнегүләр, компьютер, интерактив такта, презентация.

Дәрес барышы:

I Оештыру өлеше

а) Уңай эмоцианаль халәт булдыру (шигырь)

-Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек?

Яхшы кәеф белән дәресебезне башлыйбыз. Уңышлар сезгә!

б) «Сорау- җавап» уены.

-Укучылар, дәресебезне гадәттәгечә «Сорау-җавап» уеныннан башлыйбыз. (Бүгенге көн, һава торышы, табигать турында сөйләшү)

II Актуальләштерү

а) Фонетик күнегү. Авазларны дөрес итеп әйтү. Укытучы укый.

Дуслык яшәргә кирәк җир йөзендә,

Дуслар кирәк һәрбер кешегә

Дуслык булса яшәү күңелле дә,

Гөрләп бара һәрбер эшең дә.

- Укучылар, бу шигырьнең мәгънәсен аңладыгызмы? Нәрсә турында сүз бара? Кыскача гына үз сүзләрегез белән русча әйтеп бирегез.

б) Сәнгатьле итеп күмәк уку.

III Дәреснең темасын ачыклау, максат һәм бурычларны билгеләү

а) Рәсем буенча эш.

- Укучылар, экранга игътибар итегез әле. Шигырь эчтәлегенә туры килгән кайсы рәсемне сайлар идегез? Ни өчен бу рәсемне сайладыгыз?

- Бу кемнәр? (Дуслар)

- Алар нишлиләр? (Алар көләләр, шатланалар, күңел ачалар)

- Алар нинди? (Шат, көләч)

-Ничек уйлыйсыз аларга күңеллеме? (Әйе, аларга бик күңелле.)

-Димәк, бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (Дуслык турында)

- Әйе, дуслык темасын кабатлыйбыз. Алдагы дәресләрдә өйрәнгәннәрне искә төшерәбез һәм гомумиләштерәбез.

- Укучылар, кешегә дуслар кирәкме? Ни өчен? (Дуслар белән күңелле)

-Дәресебезнең темасы да «ДУСЛАР БЕЛӘН КҮҢЕЛЛЕ» дип атала. Ә сез дуслыкны нинди символлар, предметлар белән чагыштырыр идегез? (Кояш, чәчәк.....h.б.)

- Әйе. Тактага игътибар итсәгез, биредә кояш сурәтләнгән. Кояшның йөзендә дәресебезнең максаты, ә нурларында сораулар һәм биремнәр бирелгән. Шуларны үтәп, максатка ирешербез, дип уйлыйм.

Максат: ДУСЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛӘРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ.

-Укучылар, сезнең өстәлләрдә бәяләү кәгазьләре бар. Һәр биремгә баллар куеп барырсыз.

IV Укучыларның терәк белемнәрен яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү

1. Өй эшен тикшерү. «Тәрҗемәче» интерактив уены. (Кояшның беренче нуры ачыла. Дус нинди була?)

-Укучылар, бүгенге дәрескә өй эше бар идеме? (Сүзләр өйрәнергә)

-Өй эшен интерактив уен ярдәмендә тикшерәбез. Кеше холкына хас булган уңай һәм тискәре сыйфатларны 2 төркемгә бүлеп урнаштырыгыз.

Тырыш, ярдәмчел, ялкау, ягымлы, саран, тәрбияле, юмарт, игътибарлы, ялганчы, шаян, гадел, ышанычлы, усал.

- Сез ничек уйлыйсыз, дус нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? (Тырыш, ярдәмчел, ягымлы ...h.б)

V Белемнәрне яңа ситуациядә иҗади куллану һәм эзләп табу (проблемалы биремнәр)

2. Төркемнәрдә эш. Портрет буенча кешенең тышкы кыяфәте турында сөйләү.

Эшне тикшерү. Төркемнән бер укучы чыгып укый, калганнар тикшереп бара.

(Укытучы билге куя. Югары балл-5)

3. Индивидуаль эш. Карточкалар ярдәмендә грамматик бирем башкару. (Кояшның икенче нуры ачыла. Дустыңны яхшы беләсеңме?)

Нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстәгез:

1) Минем дустым шәһәр...(кайда?) яши.

2) Ул 5нче сыйныф...(кайда?) укый.

3) Дустым...(кемнең?) яраткан шөгыле- йөзү.

4) Ул бассейн...(кая?) йөри.

5)Минем дустым ярдәмчел, шуңа күрә дустым...(кемне?) хөрмәт итәм.

- Укучылар, эшләрегезне бер-берегезгә тапшырыгыз, тикшерегез һәм билге куегыз. (Партадаш укучылар бер-берсенә билге куя. Һәр дөрес җавапка 1балл куела)

- Укучылар, җөмләләрне кычкырып укыгыз, төшеп калган кушымчаларны әйтегез җөмләләрне тәрҗемә итегез.

4. Карточкалар ярдәмендә грамматик бирем башкару. (Җөмләдә сүз тәртибе) Индивидуаль эш. (Кояшның өченче нуры ачыла. Дуслар бергә нишлиләр?)

-Укучылар, җөмләдәге сүзләр адашканнар. Аларга үз урыннарын табарга ярдәм итегез. Һәр сүзнең өстенә тәртип буенча саннар куеп чыгыгыз.

1) ял, бергә, Дуслар, итәләр. (3214

2) шуалар, бергә, көне, чаңгы, Кыш.

3) кинога, бергә, Дуслар, йөриләр.

4) һәрвакыт, дус, ярдәм итә, Чын.

5) дәрес, Дуслар, әзерлиләр, бергә.

- Укучылар, эшегезне экрандагы җаваплар белән чагыштырып тикшерегез һәм билге куегыз. (Үзбәя. Һәр дөрес җавапка 1балл куела)

V Ял минуты. «Кәрия-Зәкәрия» җыры

5. **Парларда эш.** Ситуатив күнегүләр башкару.

Предложи другу:

- вместе готовить уроки;

- пойти в школу;

- покататься на лыжах, определите время и место;

- сходить в кинотеатр.

Спроси у друга:

- играет ли он зимой на улице?;
- узнай, как он любить играть?;
- на какой кружок он ходит?

- Димәк, укучылар, дуслар буш вакытта бергә нишлиләр? (Дуслар бергә ял итәләр, урамда уйныйлар, дәрес әзерлиләр, кинога, театрга, түгәрәккә йөриләр)

(Укытучы билге куя. Югары балл-5)

6. Төркемнәрдә эш. Диалог төзү. (Кояшның дүртенче нуры ачыла. Дустың турында сөйлә)

- .....?

- Әйе, минем дустым бар.

- .....?

- Без мәктәптә таныштык.

- .....?

- Аңа 11 яшь.

- .....?

- Ул «Адымнар-Алабуга» күптелле белем бирү комплексында укый.

- Дустың нинди?

- .....

- Сез бергә нишлисез?

- ....

VI Рефлексия

7. Күмәк эш. Сораулар ярдәмендә хикәя төзү.

1. Дустыңның исеме, яше, кайда укуы, яшәве турында әйт.

2. Сез кайчан һәм кайда таныштыгыз?

3. Ул нинди? (кыйфәте, холкы)

4. Дустыңның яраткан шөгыле бармы?

5. Сез буш вакытыгызда бергә нишлисез?

6. Дуслар ни өчен кирәк?

VII Билге кую. Балларны санау

20-18 балл - «5» ле

17-14 балл - «4» ле

13-10 балл- «3»ле

9 баллдан түбән- «2»ле

VIII Өй эше

1. «Минем дустым» темасына хикәя язарга.

2. Дустыңның портретын ясарга һәм сөйләргә.

Йомгаклау. «Туган көн» җырын башкару.